Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

2014 елның 5 ноябре 20№

«Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, һәм «Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү турында нигезләмә

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 сентябрьдәге «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 1065 номерлы Әмерен исәпкә алып, Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Раслarга:

«Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, һәм «Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү турында нигезләмәне

2.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

3. Әлеге карар аңа имза куйган көннән үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы: Ф.Б.Вафина

Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Советының 2014.05.11, 20№ карарына1 нче кушымта

**Әлки муниципаль районы депутаты статусы турында нигезләмә «Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм «Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә түбәндәгеләрне тикшерү тәртибен билгели:

а) Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Советы карары нигезендә тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын:

хисап датасына муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнарның (алга таба - гражданнар) ;

хисап чорында һәм хисап чорына кадәрге ике елда муниципаль хезмәткәрләрнең;

б) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль хезмәткә кергәндә гражданнар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

в) муниципаль хезмәткәрләрнең әлеге пунктта каралган чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу таләпләрен, алар тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән бурычларны үтәүне (алга таба - хезмәт тәртибенә карата таләпләр) тикшерүне гамәлгә ашыру өчен нигез булып торган мәгълүматны өч ел дәвамында үтәве (алга таба-хезмәт тәртибенә карата таләпләр).

2. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында каралган тикшерү яллаучы вәкиленең (җирле үзидарә органы җитәкчесенен) яки мондый вәкаләтләр яллаучы вәкиле (җирле үзидарә органы җитәкчесе) тарафыннан бирелгән вазыйфаи затның карары буенча гамәлгә ашырыла.

Карар һәр гражданга яисә муниципаль хезмәткәргә карата аерым кабул ителә һәм язма рәвештә рәсмиләштерелә.

3.Әлеге Нигезләмәнең 1 пункты нигезендә граждан яисә муниципаль хезмәткәрнең дөрес булмаган яки тулы булмаган язмача бирелгән мәгълүматы тикшерү өчен нигез булып тора;

4. Әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында каралган мәгълүмат түбәндәгечә бирелергә мөмкин:

а) хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан;

б) законнар нигезендә башка чыганаклар тарафыннан.

5. Аноним характердагы мәгълүмат тикшерү өчен нигез була алмый.

6. Тикшерү аны уздыру турында карар кабул ителгән көннән алып 60 көннән артмаган вакытта гамәлгә ашырыла. Тикшерү срогы аны уздыру турында карар кабул иткән затлар тарафыннан 90 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин.

7. Тикшерү гамәлгә ашырылганда яллаучының вәкиле (җирле үзидарә органы җитәкчесе) яки мондый вәкаләтләрне яллаучы вәкиле (җирле үзидарә органы җитәкчесе) биргән вазыйфаи зат хокуклы:

а) граждан яисә муниципаль хезмәткәр белән әңгәмә уткәрергә;

б) граждан яисә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында тапшырган белешмә һәм өстәмә материалларны өйрәнергә;

в) граждан яисә муниципаль хезмәткәрдән тапшырган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр һәм материаллары турында белешмәләр буенча аңлатмалар алырга;

г) билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына, башка федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм җәмагать берләшмәләренә (алга таба - дәүләт органнары һәм оешмалары) аларда булган белешмәләр турында мөрәҗәгать җибәрергә: гражданның яисә муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, гражданның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы турында; муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү турында;

д) физик затлар турында белешмә тупларга һәм аларның ризалыгы белән мәгълүмат алырга;

е) коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә граждан яисә муниципаль хезмәткәр тапшырган белешмәләрне анализлауны гамәлгә ашырырга.

8. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы "г" пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә күрсәтелә:

а) мөрәҗәгать җибәрелә торган дәүләт органы яисә оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б) нигезендә мөрәҗәгать җибәрелә торган хокукый акт;

в) тикшерелүче гражданның яисә муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының, Россия

Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә тапшырган гражданның белешмәләренең тулылыгы һәм дөреслеге яисә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәмәү турында белешмәләр булган муниципаль хезмәткәрнең шәхесне таныклаучы документ, фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, теркәлү, яшәү һәм (яисә) булу урыны, вазыйфасы һәм эш урыны (хезмәт), төре һәм реквизитлары, керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

г) тикшерелергә тиешле белешмәләрнең эчтәлеге һәм күләме;

д) соратып алынучы белешмәләрне тапшыру срогы;

е) мөрәҗәгать әзерләүче вазыйфаи затның фамилиясе, инициаллары һәм телефон номеры;

ё) салым түләүченең идентификация номеры (мөрәҗәгать Россия Федерациясе салым органнарына юлланган очракта);

ж) башка кирәкле белешмәләр.

9. Эшкә алучының вәкиле (җирле үзидарә органы җитәкчесе) яки мондый вәкаләтләр яллаучының вәкиле (җирле үзидарә органы җитәкчесе) тарафыннан бирелгән вазыйфаи зат тәэмин итә:

а) муниципаль хезмәткәргә аңа карата тикшерү башлануы турында язма рәвештә хәбәр итү һәм аңа әлеге пунктның «б» пунктчасының эчтәлеген аңлату - тиешле карар алган көннән алып ике эш көне дәвамында;

б) муниципаль хезмәткәр мөрәҗәгате буенча әлеге Нигезләмә нигезендә бирелә торган белешмәләрнең нинди булуы һәм хезмәт тәртибенә карата нинди таләпләр куелуы турында әңгәмә муниципаль хезмәткәр мөрәҗәгатеннән соң җиде эш көне эчендә, ә җитди сәбәп булган очракта-муниципаль хезмәткәрләр белән килешенгән вакытта үткәрелә.

10. Тикшерү тәмамлангач, яллаучының вәкиле (җирле үзидарә органы җитәкчесе) яки мондый вәкаләтләрне яллаучы вәкиле (җирле үзидарә органы җитәкчесе) биргән вазыйфаи зат муниципаль хезмәткәрне тикшерү нәтиҗәләре белән дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарын үтәп таныштырырга тиеш.

11. Муниципаль хезмәткәр хокуклы:

а) тикшерү барышында һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча язма рәвештә аңлатма бирергә;

б) өстәмә материал тапшырырга һәм алар буенча язма рәвештә аңлатма бирергә;

в) әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы "б" пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча аның белән әңгәмә үткәрү турында яллаучы вәкиленә (җирле үзидарә органы җитәкчесенә) яисә вазыйфаи затка үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә.

12. Муниципаль хезмәткәрнең әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында күрсәтелгән аңлатмасы тикшерү материалларына теркәлә.

13. Тикшерү уздыру чорына муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасыннан аны үткәрү турында карар кабул

ителгән көннән алып 60 көннән дә артмаган вакытка читләштерелергә мөмкин. Күрсәтелгән срок тикшерү үткәрү турында карар кабул иткән зат тарафыннан 90 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәткәрне биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан читләштерү чорына ул биләгән вазыйфа буенча акчалата түләү саклана.

14. Тикшерү нәтиҗәләре турындагы белешмәләр, аны үткәрү турында карар кабул иткән затның язма ризалыгы белән Россия Федерациясенең шәхси белешмәләр һәм дәүләт сере турындагы законнарын үтәп, тикшерү үткәрелгән гражданга яисә муниципаль хезмәткәргә, тикшерү үткәрү өчен нигез булган мәгълүматны биргән хокук саклау һәм салым органнарына, башка чыганакларга, Россия Федерациясенең шәхси белешмәләр һәм дәүләт сере турындагы законнарын үтәп хәбәрнамә җибәрелә.

15. Әлеге Нигезләмәнең 1 пункты нигезендә тикшерү үткәрү өчен яллаучының (җирле үзидарә органы җитәкчесе) вәкиле (җирле үзидарә органы җитәкчесе) тарафыннан вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат тикшерү үткәрү турында карар кабул иткән затка аның нәтиҗәләре турында доклад тапшыра. Шул ук вакытта докладта түбәндәге тәкъдимнәрнең берсе булырга тиеш:

а) гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләү турында;

б) гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләүдән баш тарту турында;

в) муниципаль хезмәткәргә карата юридик җаваплылык чараларын куллану өчен нигезләр булмау турында;

г) муниципаль хезмәткәргә юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

д) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссиягә тикшерү материалларын бирү турында.

15.1. Гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куйган вазыйфаи зат әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән докладны һәм тиешле тәкъдимне карап, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куярга;

б) гражданны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләүдән баш тартырга;

в) муниципаль хезмәткәргә карата юридик җаваплылык чараларын кулланырга;

г хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссиягә муниципаль хезмәткәрләрне тикшерү материалларын тапшырырга.

16. Тикшерү барышында җинаять яисә административ хокук бозу билгеләре барлыгы турында дәлилләүче хәлләр ачыкланганда, бу материаллар үз компетенцияләре нигезендә дәүләт органнарына тапшырыла.

17. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең төп нөсхәләре муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси эшләренә кушып бирелә.

18. Тикшерү материаллары ул тәмамланган көннән алып өч ел дәвамында саклана, шуннан соң архивка тапшырыла.